МИНИСТЕРСТВО ЗДРАВООХРАНЕНИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

15.04.2021 г. Казань № 695

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының 31.08.2018 ел, №1947 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында «Федераль законның 22 һәм 48 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 27 октябрендәге 346-ФЗ номерлы Федераль закон кабул ителүгә, «Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» Россия Федерациясе Президентының 2020 елның 6 октябрендәге 616 номерлы Указын һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә һәм дәүләт органнарының кадрлар резервына кертүгә конкурслар үткәрүнең Бердәм методикасына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 24 сентябрендәге 1546 номерлы карарын чыгаруга бәйле рәвештә боерам:

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының 31.08.2018 ел, № 1947 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2 пунктының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Конкурс конкурсларда катнашуга кертелгән (алга таба - кандидатлар) Россия Федерациясе гражданнарының (дәүләт граждан хезмәткәрләренең) һөнәри дәрәҗәсен, шулай ук аларның тиешле граждан хезмәте вазыйфаларын биләү өчен билгеләнгән квалификация таләпләренә туры килүен (алга таба - квалификация таләпләре, кандидатларны бәяләү) бәяләүдән гыйбарәт.»;

пункт 2.1 түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Министр карары буенча конкурсларны нәтиҗәле оештыру максатыннан, Министрлыкта төрле категория һәм граждан хезмәте вазыйфаларының төрле

төркемнәре өчен берничә конкурс комиссиясе төзелергә мөмкин.»;

пункт 2.4 түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4. Конкурс комиссиясе составына министр, Министрлык боерыгы белән билгеләнгән Министрлык граждан хезмәткәрләре (кадрлар бүлеге, Медицина эшчәнлегенең стандартларын һәм сыйфатын тикшерү идарәсе, Эшләр идарәсе, Икътисади анализ һәм фаразлау идарәсе, Дәвалау һәм профилактика ярдәме идарәсе, махсус программаларны һәм проектларны эшләү һәм тормышка ашыру бүлеге) һәм граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын (кадрлар резервына кертү) биләп торуга конкурс үткәрелә торган Министрлыкның структур бүлекчәсе җитәкчесе керә, Министрлык каршындагы Иҗтимагый совет вәкилләре, шулай ук конкурс комиссиясе составына кертелүче бәйсез экспертлар - кадрлар технологияләре һәм граждан хезмәте мәсьәләләре буенча, граждан хезмәткәрләренең һөнәри хезмәт эшчәнлегенең тиешле өлкәләрендә һәм төрләрендә белгечләр булып торалар фәнни, мәгариф һәм башка оешмалар вәкилләре керә.

Министрлык каршындагы Иҗтимагый совет вәкилләренең һәм бәйсез экспертларның гомуми саны Конкурс комиссиясе әгъзаларының гомуми саныннан кимендә дүрттән бер өлешен тәшкил итәргә тиеш.

Конкурс комиссиясе составына кертелгән Министрлык каршындагы Иҗтимагый совет вәкилләре әлеге Совет карары белән министр запросы буенча билгеләнә.

Конкурс комиссиясе составына кертелә торган фәнни, мәгариф һәм башка оешмалар вәкилләре Татарстан Республикасы Президенты каршындагы дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты тарафыннан бәйсез экспертларның шәхси мәгълүматларын күрсәтмичә, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртипне исәпкә алып кабул ителгән Татарстан Республикасы норматив хокукый актында билгеләнгән тәртиптә министр запросы буенча чакырыла һәм сайлап алына.

Бәйсез экспертның Конкурс комиссиясендә гомуми булу вакыты өч елдан артмаска тиеш. Әлеге срокны исәпләү бәйсез экспертның конкурс комиссиясе составына беренче кертелгәннән бирле гамәлгә ашырыла. Әлеге бәйсез экспертны конкурс комиссиясе составына кабат кертү Конкурс комиссиясендә булу вакыты тәмамланганнан соң өч елдан соң гына гамәлгә ашырылырга мөмкин.

Министрлыкның конкурс һәм аттестация комиссияләрендә бәйсез эксперт булу срогы өч елдан артмаска тиеш.»;

пункт 2.7 түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Конкурс комиссиясе әгъзасы яисә кандидат тәкъдиме буенча сәбәбне (нигезләнешен) күрсәтеп, конкурс комиссиясе тарафыннан видеоконференция форматында (техник мөмкинлек булганда) утырыш уздыру турында карар кабул ителергә мөмкин.»;

пункт 3.4:

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«хезмәт (эш) урыны буенча нотариаль яки кадрлар хезмәте раслаган хезмәт кенәгәсенең күчермәсе һәм (яисә) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматлар һәм (яисә)

гражданның хезмәт (эш) эшчәнлеген раслаучы башка документлар (хезмәт (эш) эшчәнлеге беренче тапкыр башкарыла торган очраклардан тыш);»

җиденче абзацта «Эш (хезмәт) урыны буенча» сүзләрен «Хезмәт (эш) урыны буенча» сүзләренә алмаштырырга);»;

пункт 4.4 пунктча 4.4.11 тугызынчы абзацында «10 балл» сүзләреннән соң «минималь – 0 балл» сүзләрен өстәргә.

Министр М.Н.Садыйков